КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 23 сентябрь г.Казань № 861

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2014 ел, 8 май, 307 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2014 ел, 8 май, 307 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 8 октябрь, 744 нче; 2015 ел, 25 февраль, 113 нче; 2015 ел, 25 апрель, 286 нчы; 2016 ел, 8 февраль, 78 нче; 2016 ел, 6 август, 532 нче; 2017 ел, 13 гыйнвар, 5 нче; 2017 ел, 10 июль, 469 нчы; 2017 ел, 24 ноябрь, 901 нче; 2018 ел, 23 апрель, 279 нчы; 2018 ел, 25 июнь, 511 нче; 2018 ел, 15 декабрь, 1141 нче; 2019 ел, 2 сентябрь, 766 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмәдә:

3.1 нче пунктта «03.05.05» саннарын «03.05.04» саннарына алыштырырга;

3.1 нче пунктның 3.1.6 нчы пунктчасында «тәкъдимнәр сорау үткәрү турындагы документларны» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.1 нче пунктның 3.1.9 нчы пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

3.14 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.14. Дәүләт комитеты үз компетенциясе кысаларында түбәндәгеләр белән хезмәттәшлек итә:

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән финанс-бюджет өлкәсендә контроль функциясен гамәлгә ашырганда (01.02.01);

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы белән юстиция өлкәсендә

идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (02.03);

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы белән мәгълүматлаштыру белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.15);

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белән Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәт белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.07);

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белән хезмәт белән идарә итү функциясен тормышка ашырганда (01.13);

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән социаль-икътисадый программалаштыру функциясен гамәлгә ашырганда (01.01);

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы белән энергия һәм ресурсларны саклау белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.14);

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты белән архив эше белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.17).»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары, Татарстан Республикасы бюджет учреждениеләре ихтыяҗлары өчен кайтартучыларны (подрядчыларны, башкаручыларны) үзәкләштереп билгеләүне оештыру һәм алар өчен Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты кайтартучыларны (подрядчыларны, үтәүчеләрне) билгеләү функцияләрен гамәлгә ашыра торган Татарстан Республикасы заказчылары ихтыяҗлары өчен кайтартучыларны (подрядчыларны, үтәүчеләрне) билгеләү тәртибен яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин